Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

**ХӘБӘР**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе шәһәр халкына һәм шәһәр территориясендә урнашкан оешмаларга, Шәһәр Советы инициативасы буенча, 2021 елның 5 мартында 14.00 сәгатьтә Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 400 зал адресы буенча Башкарма комитет бинасында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары (дәвамлылыгы якынча бер сәгать) үткәрелү турында хәбәр итә.

Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 номерлы карары белән билгеләнгән.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проектына карата тәкъдимнәр, әлеге хәбәрнең аерылгысыз өлеше булган форма буенча, 2021 елның 3 мартына кадәр бирелергә мөмкин.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проектына карата тәкъдимнәр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шәһәр Уставына, башка муниципаль хокукый актларга туры килергә тиеш.

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423805, Яр Чаллы шәһәре, Х.Туфан проспекты, 23 йорт, 372 кабинет. Элемтә өчен телефоннар: 30-56-79, 30-58-31, электрон почта адресы: nche.fbp@tatar.ru.

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында» карар проекты «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырыла һәм «Интернет» челтәрендә www.nabchelny.ru адресы буенча урнаштырыла.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү түбәндәге документлар нигезендә, 2021 елның 5 мартында 13 сәгать 00 минутта башлана:

- шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары – физик затлар өчен;
- юридик затларны дәүләти теркәү турындагы таныклык мәгълүматлары, юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ мәгълүматлары; юридик зат вәкиленең шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары – юридик зат вәкилләре өчен.

Комиссия рәисе С.Р. Мулюкова

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы хәбәргә кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проектына тәкъдимнәр кертү формасы

| Гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проектында күздә тотылган хокук нормасы | Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында» карары проектына тәкъдим ителә торган үзгәрешләр | Тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне исәпкә алып, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында» карары проектында күздә тотылган хокук нормасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |